ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 сентябрь 2026 ел № 9541

Башкарма комитетның 2020 елның 7 октябрендәге 5118 номерлы Карары белән расланган җирләрне консервацияләү проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирләрне рекультивацияләүне һәм консервацияләүне үткәрү кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 29 маендагы 781 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 7 октябрендәге 5118 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2021 елның 12 мартындагы 1710 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге 3453 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган җирләрне консервацияләү проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктның унөченче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирләрне рекультивацияләүне һәм консервацияләүне үткәрү кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 29 маендагы 781 номерлы Карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, № 22 (I өлеш), ст. 2898, 02.06.2025) (алга таба - Җирләрне консервацияләүне үткәрү кагыйдәләре);»;

2) 2.1 пунктта «РФ Хөкүмәтенең 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы Карары» сүзләрен «Җирләрне консервацияләүне үткәрү кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2.3-2.5 пунктларда «РФ Хөкүмәтенең 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы Карары» сүзләрен «Җирләрне консервацияләүне үткәрү кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга;

4) 2.9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) консервация проектында каралган чаралар җирләрнең деградацияләнү дәрәҗәсен киметү, аларның алга таба деградацияләнүен һәм (яки) бозылган җирләрнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау максатларына ирешүне тәэмин итмиләр;<br>4) мондый җирләрне 15 ел дәвамында рекультивацияләү юлы белән, аларның торышын Җирләрне консервацияләү кагыйдәләренең 5 һәм 6 пунктларында каралган җирләр сыйфатына кадәр торгызу мөмкин булган җирләргә карата җирләрне консервацияләү проекты тәкъдим ителгән;<br>3) җирләрне консервацияләү проектында каралган консервацияләнә торган җирләрнең һәм җир участокларының мәйданы җирләрне консервацияләүне үткәрү таләп ителә торган җирләрнең һәм җир участокларының мәйданына туры килми;<br>4) җирләрне консервацияләү проектының «Аңлату язуы» бүлегендә консервацияләнә торган җирләр һәм җир участоклары турында дөрес булмаган мәгълүматлар бар | Җирләрне консервацияләүне үткәрү кагыйдәләре |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе башлыгы А.З. Хамматовка йөкләргә.




Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов